**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КАРАМАЛЫ ТАУ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2019 елның 3 июне №181

Һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалын үстерүне кызыксындыру максатларында Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге алган башка бюджетара трансфертлар хисабына гамәлгә ашырыла торган чыгымнарны җибәрү турында

«Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 28 мартындагы 233 номерлы карары, "Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында" Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2019 елның 26 апрелендәге 379 номерлы карары нигезендә Зеленодольск муниципаль районының Карамалы Тау шәһәр җирлеге җитәкчесе мәгълүматын тыңлап тикшергәннән соң, Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советы карар итте:

1. һөнәри керемгә салым потенциалын үстерүне кызыксындыру максатларында Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерүне финанслар белән тәэмин итүгә Зеленодол муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге тарафыннан алынган башка бюджетара трансфертлар хисабына гамәлгә ашырыла торган чыгымнар юнәлешен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru),

махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштырырга: Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы, Беренче Май ур., 70нчы йорт, җирле үзидарә бинасы, Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы, Беренче Май ур., 70 нчы йорт (җирлекнең административ бинасы), Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы, Беренче май ур., 30 нчы йорт, «Гадел» кибете янында мәгълүмат тактасы, Карамалы Тау штп, Беренче Май ур., вокзал алды мәйданчыгында мәгълүмат стенды, Кузнечная ур., 13 а йорт, «Диана» кибете янында мәгълүмат стенды, Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы, Кузнечная ур., 16 а йорт, «Рубин» кибете янында мәгълүмат стенды, Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы, Б.Кочемирская ур., 2а, «ЮСОН» кибете янында мәгълүмат стенды, Протоповка авылы, Кооператив урамы, 15 нче йорт, ИП Яфизов кибете янында мәгълүмат тактасы, Олы Ходяшево авылы, Үзәк урам, 42 нче йорт, ИП Навасардян кибетендә мәгълүмат тактасы.

**Җирлек башлыгы,**
**Совет рәисе:** **Ю. М. Некрасова**